# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 24 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

"Мәдәният турында" 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 7; 2000, № 12 (11) (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 7-8 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"11 статья. **Татарстан Республикасында китапханә, музей, архив һәм башка фондлар**";

б) түбәндәге эчтәлекле икенче өлеш өстәргә:

"Дәүләт (муниципаль) мәдәният учреждениеләренең оператив идарәсендәге Россия Федерациясе Музей фонды предметлары, Россия Федерациясе Архив фонды һәм милли китапханә фонды документлары дәүләт (муниципаль) мәдәният учреждениеләренең аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтенә кертелергә тиеш.";

2) 21 статьядагы алтынчы өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Мәдәният оешмалары Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда һәм тәртиптә үз илебез һәм чит ил банклары кредитыннан файдаланырга, валютаны сатырга һәм сатып алырга мөмкин.";

3) 23 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"23 статья. **Дәүләт һәм муниципаль мәдәният оешмаларының керемнәр**

**китерә торган эшчәнлеге**

Дәүләт һәм муниципаль мәдәният оешмалары Россия Федерациясе законнары нигезендә керемнәр китерә торган эшчәнлек алып барырга хокуклы.";

4) 27 статьяда:

а) икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Юридик һәм физик затлар мәдәният объектларында туристлык-экскурсия эшчәнлеген бары тик мәдәният органнары һәм оешмалары белән шартнамә нигезендә генә гамәлгә ашыралар.";

б) өченче өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

"Китапханәләр һәм китапханә эше турында" 1998 елның 21 октябрендәге 1818 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 11; 2001, № 1-2; 2004, № 2 (I өлеш), 2006 № 7 (I өлеш), 2010, № 5 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 статьяның беренче өлешендәге алтынчы абзацында "эшкуарлык эшчәнлеге" сүзләрен "керем китерә торган эшчәнлек" сүзләренә алмаштырырга;

2) 22 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Россия Федерациясе законнары нигезендә һәм үз компетенцияләре чикләрендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, муниципаль берәмлекләр, шулай ук юридик һәм физик затлар Татарстан Республикасында китапханәләрнең гамәлгә куючылары була алалар.";

3) 24 статьяга түбәндәге эчтәлекле икенче өлеш өстәргә:

"Дәүләт (муниципаль) китапханәләренең оператив идарәсендәге милли китапханә фонды документлары дәүләт (муниципаль) китапханәләренең аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтенә кертелергә тиеш.".

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 15 марты
№ 2-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ПРЕЗИДЕНТ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ